| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

20.02.2015 Девәтернә авылы № 36-2

Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 16 июнендәге 25-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Положениегә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында" 2014 елның 22 декабрендәге 431-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2014 елның 16 июнендәге 25-1 номерлы Девәтернә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә (17.10.2014 елларга үзгәрешләр белән) муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.1 пунктының 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 11.1 пунктындагы 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтеннән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һөнәр берлекләреннән тыш) катнашырга, әгәр федераль законнарда яисә тәртиптә булса һәм Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә башкасы каралмаган булса, аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса»;

1.3. 28.1.2 пунктына «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирүче» сүзләрен я аларга картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән» сүзләрен «картлык буенча хезмәт пенсиясенә «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә

картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга, я аларга картлык буенча вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән».

1.4 28.1.3 пунктында «картлык буенча хезмәт пенсиясе» сүзләрен «картлык буенча иминият пенсиясе» сүзләренә алмаштырырга.

1.5 28.2. пунктында «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган йә картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) буенча вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләү» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга, я картлык буенча иминият пенсиясе яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнә».

1.6 пунктта «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирүче я картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясе өлешендә) вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгәндә» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга, я аларга картлык буенча картлык буенча иминият пенсиясе яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнә.

1.7 пунктта «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнгән картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең беркетелгән база күләменнән артмый, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминиятләштерү өлешенең күрсәтелгән теркәлгән база күләменә тигез күләмдә түләнә» сүзләрен «картлык буенча иминият пенсиясенең иминиятләштерү өлешенә теркәлгән түләүдән артмый» сүзләренә алмаштырырга;

1.8 пунктта 28.7 пунктында «картлык буенча хезмәт пенсиясенә» сүзләрен «картлык буенча иминият пенсиясенә» сүзләренә алмаштырырга.

1.9 пунктта 28.16 пунктында «(инвалидлык буенча хезмәт пенсиясеннән тыш), хезмәт пенсиясенә (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) айлык өстәмә түләүне (инвалидлык буенча иминият пенсиясеннән тыш), иминият пенсиясенә айлык өстәмә түләүне» сүзләрен «(инвалидлык буенча иминият пенсиясеннән тыш) сүзләренә алмаштырырга.

1.10. 28.18 пунктта «хезмәт пенсиясе» сүзләрен «иминият пенсиясе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Девәтернә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Әгерже муниципаль районының agryz.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Девәтернә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Йосыпов